**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

---

12.12.2023 ел №215

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 30 сентябрендәге № 63 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроле турында» 2020 елның 31 июлендәге № 248-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 12.10.2023 ел, № 01-54/7098 «Риск индикаторлары турында» гы хатын үтәү өчен Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 30 сентябрендәге № 63 номерлы карары белән (район Советының 2022 елның 27 гыйнварындагы №90 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган «Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль чараларын үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары» 2 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Гражданнардан (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен билгеләргә мөмкинлек бирә торган ысул белән килгән) яки күпфатирлы йортта бина хуҗалары

булган оешмалардан, күпфатирлы йорт биналарын кулланучы гражданнардан алдагы шундый ук чор белән һәм (яки) алдагы календарь елның шул ук чоры белән чагыштырганда вакыт берәмлегендә (ай, квартал) дәүләт торак күзәтчелеге органы, муниципаль торак контроле органы адресына мөрәҗәгатьләр, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясының 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотучы затлар тарафыннан бозу фактлары турында дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, дәүләт мәгълүмат системаларыннан алынган мәгълүмат санының өч тапкыр һәм аннан да күбрәк артуы.

3. Россия Федерациясе Торак Кодексының 165 статьясының 5 өлеше нигезендә билгеләнгән тәртипкә, формаларга, срокларга һәм вакытлычалыкка ярашлы рәвештә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматның өч һәм аннан да күбрәк ай дәвамында актуальләшмәве.

4. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биш тапкырдан артык ремонт бригадасы чакырыла.

5.Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы Рәисе Р.Т. Айбатов